**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 3 апрель № 207

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар план-графигын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2015 ел, 12 сентябрь, 665 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар план-графигын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар план-графигын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2015 ел, 12 сентябрь, 665 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар план-графигын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта:

түбәндәге эчтәлекле «$б^{1}$» пунктчасын өстәргә:

«$б^{1}$) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, Контракт системасы турындагы законның 15 статьясындагы 2.1 һәм 6 өлешләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган сатып алулардан тыш, – унитар предприятиенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын раслаган көннән;»;

«в» пунктчасында «, Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 нче пунктка «әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында» сүзләреннән соң «әлеге Тәртипнең 2 нче пунктындагы «$б^{1}$» пунктчасында күрсәтелгән заказчылардан тыш» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 3.1 нче пункт өстәргә:

«3.1. Сатып алулар план-графиклары әлеге Тәртипнең 2 нче пунктындагы «б[1]» пунктчасында күрсәтелгән заказчылар тарафыннан, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон проекты Татарстан Республикасы Дәүләт Советына карап тикшерүгә кертелгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, сатып алулар планы нигезендә ел саен чираттагы финанс елына формалаштырыла һәм әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында билгеләнгән вакыт эчендә сатып алулар план-графикларын тәгаенләгәннән соң (кирәк булган очракта) һәм унитар предприятиенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын раслаганнан соң сатып алулар план-графикларын раслыйлар.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\207.doc